**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Комыргуҗа авыл җирлеге Советы Карары**

09.03.2021 ел № 20

**Комыргуҗа авыл җирлеге Советының 2018 елның 2 июлендә кабул ителгән 78/1 номерлы «Комыргуҗа авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге турындагы нигезләмәне раслау хакындагы карарына үзгәрешләр кертү турында»**

"Россия Федерациясе Хөкүмәте актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында" 26.10.2020 ел, № 1742 РФ Хөкүмәте Карары нигезендә, федераль башкарма хакимият органнары актларының мәҗбүри таләпләрен үз эченә алган кайбер актларын һәм аерым нигезләмәләрен юкка чыгару турында, Федераль Дәүләт транспорт күзәтчелеген, федераль дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда тикшереп тору чараларын үткәргәндә аларның үтәлеше бәяләнә торган аерым нигезләмәләрен юкка чыгару турында, шулай ук транспорт чараларын техник карау өлкәсендә мәҗбүри таләпләр" (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) нигезендә һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Уставы нигезендә Комыргуҗа авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1.”Комыргуҗа авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге турындагы нигезләмәне раслау хакында” Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Советының 2018 елның 2 июлендәге 78/1 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 статьясының 3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 3.2. "Автомобиль юлларының техник торышын бәяләү тәртибе турында" 07.08.2020 ел, № 288 Россия Федерациясе Транспорт министрлыгы боерыгы.»

1. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Низамиев